**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Мәлбагыш авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Мәлбагыш авылы №14 «16» декабрь 2020 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Мәлбагыш авыл Советының 2020 елның 25 февралендәге 163 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Мәлбагыш авылы җирлегенең бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турындагы нигезләмәне раслау хакында» карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Мәлбагыш авыл җирлегенең бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турында нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында (24.04.2020 №170, 15.06.2020 №173 карарлар редакциясендә).

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, 2020 елның 31 июлендәге 263-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль закон нигезендә,

Мәлбагыш авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Мәлбагышавыл Советының 2020 елның 25 февралендәге 163 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Мәлбагыш авылы җирлегенең бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турындагы нигезләмәне раслау хакында» карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Мәлбагыш авыл җирлегенең бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турында нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында (24.04.2020 №170, 15.06.2020 №173 карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.1. 36 статьяның 2 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«2. Җирлек Советы керемнәренең гомуми күләмен үзгәртүгә китерә торган һәм бюджет турындагы карар проектын җирлек Советына керткәннән соң кабул ителгән хокукый актлар нигезләмәләре агымдагы финанс елына һәм план чорына бюджетка үзгәрешләр кертkәндә, агымдагы финанс елы күрсәткечләре өлешендә чираттагы финанс елында исәпкә алына.».

1.2. 44 статьяның 2 пунктын үз көчен югалткан дип танырга.

1.3. 56 статьяның 1 пунктындагы 2 абзацында «яисә Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә әлеге орган исеменнән эш итәргә вәкаләтле бүтән зат» сүзләрен өстәргә.».

1.4. 57 статьяның икенче абзацында «максатчан билгеләнештәге субсидияләр, субвенцияләр, башка бюджетара трансфертлар бирү максатларында күрсәтелгән акчаларны бирү максатларына туры килә торган сүзләрне» сүзләренә алмаштырырга.

2. Билгеләргә: әлеге карарның 1.1, 1.2. пунктлары 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» урнаштыру юлы белән түбәндәге веб-адрес буенча игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru. һәм «Интернет» мәгълүмати-коммуникацион челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://aznakayevo.tatar.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Азнакай районы Мәлбагыш авыл җирлеге Советының бюджет, финанс, салымнар һәм икътисад мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Рәис А.Й.Әхмәтшин